СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Школьная, д.38, с.Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар　　　　　　　　　　　　Решение

«20» февраль 2023 ел.　　　　　　　　　　　　№ 2-24

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге №1-31 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Соколка авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»1-31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кушымтаның 12 статьядагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә».

1.2. Кушымтаның 12 статьясындагы 2 абзацындагы «, шәһәр округы генераль планнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгы И.Р. Сафинка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге
Советы рәисе, җирлек башлыгы /И.Р. Сафин/